**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 58
факс: 8 (84346) 2-17-57

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур.58
тел: 8 (84346) 2-10-48

2014 елның 9 декабре 56№

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

**Әлки муниципаль районы**
**Инвестиция советы төзелү турында**

«Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» Татарстан Республикасы Законын һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру, шулай ук Әлки муниципаль районының инвестиция климатын яхшырту максатларында

**карар итәм:**

1. Әлки муниципаль районы Инвестиция советын төзергә.
2. Әлки муниципаль районы Инвестиция советы турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Әлки муниципаль районы Башлыгы:** **Ф.М. Дәүләтшин**

Әлки муниципаль
районы Башлыгының 2014 елның

_____________ _____№
карарына1 нче кушымта

**Әлки муниципаль районы Инвестиция советы турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлки муниципаль районы Инвестиция советы (алга таба - Инвестиция советы) Әлки муниципаль районы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.2. Инвестиция советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Инвестицион советның төп бурычлары һәм функцияләре

Инвестицион советның төп бурычлары һәм функцияләре:

инвестиция проектларын Әлки муниципаль районы территориясендә тормышка ашыруның максатчанлыгы һәм аларны Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар акчалары исәбеннән финанслау кирәклеге (мөмкинлекләре) буенча карау һәм анализлау;

түбәндәге тәкъдимнәр эшләү:

- Әлки муниципаль районының инвестиция мәйданчыкларында потенциаль инвесторларның инвестиция проектларын урнаштыру;

- Әлки муниципаль районы башкарма хакимияте органнары һәм инвестиция процессында катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген оештыру;

- рөхсәт бирү документациясен бирү процедурасын кыскарту һәм гадиләштерү өлешендә административ киртәләрне киметү;

-Әлки муниципаль районы үсешенең өстенлекле юнәлешләре һәм иң мөһим юнәлешләрдә финанс һәм инвестиция ресурсларын координацияләү;

- Әлки муниципаль районы икътисадына инвестицияләр күләмен арттыру, уңай инвестицион климат булдыру һәм үсеш алган инвестицион инфраструктура булдыру механизмнары;

- Әлки муниципаль районы территориясендә җитештерү көчләрен рациональ урнаштыру өчен кирәкле шартлар тудыру;

- Әлки муниципаль районы территориясендә инвестиция процессларына дәүләт ярдәме һәм инвестиция активлыгын стимуллаштыру;

- федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет һәм авыл җирлекләре бюджетлары исәбеннән ярдәм ителә торган инвестиция проектларының төп критерийларына бердәм таләпләр билгеләү;

- дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын кулланып, Әлки муниципаль районында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасының инвестицион стратегиясе проектын карау. Әлки муниципаль районының инвестицион стратегиясен гамәлгә ашыру барышын һәм нәтиҗәләрен анализлау, аны үзгәртү буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм карау;

инвестиция проектларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен карау;

Әлки муниципаль районының инвестицион объектларын һәм кирәкле транспорт, энергетика, социаль һәм башка инфраструктура объектларын төзү планы проектын, шулай ук инвестицион проектлар ихтыяҗларын исәпкә алып, аны төзәтү регламентынраслау;

җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыруга вәкаләтле органның даими хисапларын карау.

## 3. Инвестиция советы хокуклары

Инвестиция советы үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкару өчен үз компетенциясе чикләрендә хокуклы:

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасының норматив хокукый базасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

үз утырышларында Инвестиция советы компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне карарга һәм алар буенча карарлар кабул итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Әлки муниципаль районындагы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмаларыннан үз компетенцияләре чикләрендә мәгълүмат соратырга һәм алырга;

Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Президенты указларын яисә күрсәтмәләрен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын яисә күрсәтмәләрен кабул итүне таләп итә торган мәсьәләләр буенча тиешле тәкъдимнәр кертергә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Әлки муниципаль районындагы җирле үзидарә органнары һәм башка орган һәм оешма җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын чакырырга.

## 4. Инвестицион совет эшчәнлеген оештыру

4.1. Инвестицион совет турында нигезләмә һәм аның составы Әлки муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана. Инвестицион совет рәисе - Әлки муниципаль районы Башлыгы.

Инвестицион совет рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Инвестицион совет утырышларын алып бара, Инвестицион совет утырышы планын раслый.

Инвестиция советы рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Инвестиция советы рәисе урынбасары башкара.

Инвестицион совет утырышларын әзерләү эшен оештыру һәм утырышларда кабул ителә торган карарларның үтәлешен тикшереп тору Инвестицион совет сәркатибы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Инвестицион совет эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча сәркатип Инвестицион совет рәисе һәм аның урынбасары йөкләмәләрен үти.

4.2. Инвестиция советы составына Әлки муниципаль районы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, инвесторлар, эшмәкәрләрнең иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре һәм экспертлар керә.

Инвестиция процессы субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар Инвестиция советы рәисенә Инвестиция советы составына керү өчен кандидатуралар буенча үз тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы.

Инвестиция советы үзенең эшчәнлеген аның утырышларында кабул ителә торган һәм Инвестиция советы рәисе раслаган эш планнары нигезендә гамәлгә ашыра.

4.3. Инвестицион совет утырышлары кирәк саен, әмма ике айга кимендә бер тапкыр уздырыла. Утырышларның көн тәртибен һәм аларны үткәрү тәртибен Инвестицион совет рәисе билгели. Инвестицион совет утырышлары «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә утырышларны он-лайн трансляцияләү белән үткәрелергә мөмкин.

4.4. Әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, Инвестиция советы утырышы тулы хокуклы дип санала.

4.5. Инвестицион совет карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Инвестицион совет рәисе һәм сәркатип имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, Инвестицион совет әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

Утырышта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда Инвестицион совет әгъзалары тигез хокукларга ия.

4.6. Совет эшендә кирәк булганда, аның составына кермәгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләре катнаша ала.

4.7. Инвестиция советы эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Әлки муниципаль районы Советы аппараты һәм Инвестиция советы эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик тәэмин итүне Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы башкара.

Әлки муниципаль районы
Башлыгының 2014 елның
_____________ _____№
карарына 2 нче кушымта

**Әлки муниципаль районы Инвестиция советы составы**

| | |
|---|---|
| Дәүләтшин Фердинат Мидхәт улы | Әлки муниципаль районы Башлыгы, Инвестицион совет рәисе |
| Никошин Александр Федорович | Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Инвестицион совет рәисе урынбасары |
| Зарипов Ринат Миңнегали улы | Инфраструктур үсеш буенча Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Сәлахов Ринас Рәис улы | Территориаль үсеш буенча Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |

| | |
|---|---|
| Шишкина<br>Наилә Исмаиловна | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы, Инвестицион совет сәркатибы |
| Гарипов<br>Әсхәт Карип улы | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы |
| Гадиев<br>Роберт Рәшит улы | Әлки районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы, (килешү буенча) |
| Гатауллин<br>Раил Мөдәрис улы | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы |
| Габидуллин<br>Илгиз Ислам улы | Әлки муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Хөснетдинов<br>Альфред Зиннур улы | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Әлки бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Нургазизов<br>Равил Мингазиз улы | Әлки районы «Чистайгаз» РЭГХ ЭҖИ РЭГС начальнигы (килешү буенча) |
| Мусин<br>Рәшит Солтанбик улы | Базарлы Матак авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Хуҗин<br>Азат Идрис улы | Татарстан Республикасы буенча «Кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» ФДБУнең Әлки районы филиалы бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Галиуллин<br>Фәрит Хаммат улы | Әлки РЭХ участогы начальнигы<br>(килешү буенча) |
| Одушкина<br>Светлана Викторовна | «Әлки үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Шалдымов<br>Вячеслав Васильевич | «Татарстан Республикасы буенча ФЯКХ 105 ЯБ ФДКУ начальнигы (килешү буенча) |
| Петров<br>Владимир Михайлович | Әлки муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Дәүлиева<br>Гөлсинә Шәйхетдин кызы | «Олимп» шәхси эшмәкәре, Эшмәкәрләр советы рәисе (килешү буенча) |